

Быел җәй Мордовиядә, Ләмберә рай-онынын Аксёново авылында Ботенроссия авыл Сабантуе узачак. Бәйрәмгә әзерлек тулы куәтенә бара. Анда vзенчәлекле осталарнын эшләнмәләре, спорт ярышлары, яшь катнашучылар очен кvнел ачу, ат чабышлары, милли аш-су тәкъдим ителәчәк. «Татар ое» этнографик кvр-гәзмәсе аеруча кызыклы булырга охшаган.      Татар орнаменты белән бизәлгән якты яшел сандык «Татар ое» этнографик кvргәзмәсенен ин кызыклы экспонатларыннан берсе булыр, могаен. Ул 19 гасыр азагы - 20 гасыр башында ясалган һәм танылган останын жылысын саклый кебек. Сандык гади тvгел, ә тарихы бар. Бу аны кvргәзмә кунаклары очен бигрәк тә кызыклы ясый. Сандыкчыкны Сергей Корешков ясаган. Бу хакта житештерvченен «С.С.Корешков» сәvдә клеймосы сойли; ул сандыкта сакланган. Ә Ләмберәдәге «Алмаз» мәдәни-спорт vзәгенә пенсионер Рәшит Янгибаев реставрацияләгән һәм бvләк иткән, дип яза «Призыв» район газетасы.

Рәшит Янгибаев уникаль экспонатнын кулына эләгvе турында болай сойли: «Бу сандыкнын тарихы бик vзенчәлекле, - ди Рәшит Ярбек улы. - Ул мина очраклы гына эләкте: бер дустым һәм сыйныфташым (ул Казанда яши) һәм анын сенлесе ата-ана йортын сатарга карар иткәч, ойләрен жыештырырга һәм аны сатуга әзерләргә ярдәм итvләрен сорадылар. Менә шунда, Мансуровлар гаиләсе йортында (безнен Ләмберә районында бик танылган гаилә), мин сандыкны таптым. Ә мин борынгы әйберләрне бик яратам, кызыксынам. Шунда дусларым аны мина бик теләп бирделәр дә. Булмаса, бу очракта сандыкны, кирәкмәгәч, чыгарып ташлар иделәр», - дип искә ала пенсионер.

Бу сандык Рәшит Ярбек улы дустынын әбисенеке булган икән. XX гасыр башында Ләмберә районы Башкарма комитетынын беренче рәисе Хосәен Мансуровка кияvгә чыкканда бу сандыкта анын бирнәсе сак-ланган. Рәшит Янгибаев сvзләренә караганда, аны әбигә 15-16 яшь булганда жыя башлаганнар. Әмма сандыкнын ана ни рәвешле эләгvе билгеле тvгел. Бәлки, ул туганнарыннан мирас итеп алынгандыр, могаен, Тvбән Новгород ярминкәсендә (ул чакта Россия империясендә ин зурлардан булган) әби очен махсус сатып алынган булгандыр. Бу ярминкәләргә Владимир губернасы Муром оязенен Загарин волосте Вырыпай авылыннан бертуган Корешковлар - Семен белән Федор vз сандыкларын сатканнар. Шуны да билгеләп vтәргә кирәк, Владимир губернасынын Муром оязе XIX гасырнын икенче яртысында - XX гасыр башында Россиядә сандыклар житештерv буенча ин зур vзәкләрнен берсе булган. Нигездә, сандыкчылар гади әйберләр ижат иткән, алар кvпләп сатып алучыга исәпләнгән. Кагыйдә буларак, алар конгырт-коричневый яки яшел тостә булганнар. Элегрәк ике яктан тоткалары булган һәм калай тасмалар ярдәмендә сетка сыман бизәлгән булган. Моннан тыш, алгы ягы тимер тасма белән яки трафарет бизәкләре очпочмак белән ныгытылган. Шунысын да

билгеләп vтәргә кирәк, сандык осталарынын эшләре арасында бай сатып алучыга житештерелгән эшләнмәләрне дә очратырга булган.
«Сандыкны реставрацияләv алдыннан мин шунда ук vзем очен житеште-рvчеләрнен маркировкасына кагылмаячакмын дип карар иттем. Ә менә калганын кvнелем теләгәнчә эшләячәкмен. Якынча реставрациягә оч ай вакыт китте. Башта сандыкны чистарттым. Ул иске иде: урыны белән чери башлаган, тимер полосаларда кvгәрек барлыкка килгән. Мин кайбер элементларын астан, эченә планкалар куеп ныгыттым. Аннары бизәvгә керештем: яшел тосне сайладым һәм vсемлек орнаменты булган татар бизәкләрен. Сул яктагы калай полосаларындагы чеканканы оригинал итеп калдырдым», - ди Рәшит Янгибаев башкарылган эшләре турында.
Сvз унаенда, Рәшит Янгибаев рестав-рациягә беркайда да ойрәнмәгән. Белеме буенча инженер-механик. Әмма Рәшит Ярбековичка ул башкарган эшләре бик ошый һәм шулай туган авылына ярдәм итvенә шат.
Рәшит Ярбекович тагын ике сандыкны реставрацияләvгә ала. Алар да борынгы. Әмма аларнын тарихы билгеле тvгел. Сандыктан тыш, Рәшит Янгибаев «Алмаз»га бик кvп борынгы әйберләр тапшырган: ухват һәм мич очен корәк, намаз уку очен келәм, хатын-кызлар кvн аяк киеме һәм читекләр, Вена стилендәге урындык.
Билгеле булганча, татар йортында сандыкларда кәләшнен бирнәсе сакланган. Гаиләдә кызлар кvп булган саен, ойдә сандыклар кvбрәк жыелган. Торле тос-тәге сандыклар бер-берсе остенә оеп куелган. Мондый сандыкларнын кvләме дә торле булырга момкин: кечкенәдән зурга чаклы. Аларда тукымалар, сол-геләр, кадерле әйберләр сакланган. Элек-электән ойләреннән сирәк чыккан татар хатын-кызлары буш вакытларында кул эшләре белән шогыльләнгәннәр: теккәннәр, чиккәннәр. Бу эшләр дә сандыкларда сакланган. Аларны туйларга яки зур бәйрәмнәргә генә тартып чыгарганнар.

**Наилә НАСЫРОВА** *тәржемәсе*